ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.01.2020 г. Заинск № 02

**«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе филиалында комплекслы сорату ярдәмендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылмый торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 06 декабрендәге 1791 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе филиалында комплекслы сорату ярдәмендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылмый торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 06 декабрендәге 1791 номерлы карарына, яңа редакциядә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген кушымта нигезендә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист
Л.М. Рахимова
3-13-37

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
09.01.2020ел №02
карарына кушымта

**«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе филиалында комплекслы сорату ярдәмендә Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелми торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге**

| № п/п | Хезмәтнең исеме |
|---|---|
| | **Муниципаль хезмәтләр** |
| 1. | Авиация эшләре башкаруга, парашюттан сикерүгә, һава судноларының күрсәтмә очышларына, пилотсыз очу аппаратлары очышларына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясе өстендә бәйләп куела торган аэростатлар күтәрелүгә рәхсәт бирү |
| 2. | Татарстан Республикасында социаль ипотека системасы буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую |
| 3. | Социаль түләүләр кулланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлегенә кертү һәм авыл җирлегендә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү турында таныклык бирү |
| 4. | Җир эшләре башкаруга ордер бирү |
| 5. | Муниципаль милек реестрына керә торган муниципаль милекне арендага бирү |
| 6. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуда арендага бирү |
| 7. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында сату юлы белән милеккә бирү |
| 8. | Крестьян (фермер) хуҗалыгы белән аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына муниципаль милектәге җир кишәрлеген милек буларак (арендага) бирү |
| 9. | Торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга милеккә (арендага) бирү |
| 10. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү |

| | |
|---|---|
| 11. | Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга индивидуаль торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү |
| 12. | «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" программасы буенча торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алу хокукы турында таныклык алуга исәпкә кую һәм таныклык бирү |
| | **Дәүләт хезмәтләре** |
| 1. | Граждан хәле актын дәүләт теркәвенә алу турында икенчел таныклык бирү |
| 2. | Язылышу турында гариза кабул итү |
| 3. | Уртак балалары булмаган, балигъ булмаган ир белән хатынның үзара ризалыгы буенча аерылышу турында гариза кабул итү |